Казан
(Идел буе)
федераль
университеты
газетасы

# DARELFӨNYN
УНИВЕРСИТЕТ

12+

№ 3
(133)

5 март
2015 ел




## *Хөрмәтле хезмәттәшләребез, гүзәл хатын-кызлар!*

Сезне чын күңелдән язгы бәйрәмнәрнең иң матуры – 8 нче март Халыкара хатын-кызлар көне белән тәбрик итәм!

Хатын-кыз мөлаемлыгының, матурлык һәм яңарышның кабатланмас бу бәйрәме – Сезгә, кайгыртучан әниләребезгә, хатыннарыбызга, хезмәттәшләребезгә, ышанычлы дусларыбызга, ихлас хөрмәт хисләребезне җиткерү өчен бер сәбәп.

Һәр ир-ат үзенең кешелек кыйммәтен хатын-кызлар янәшәсендә генә тоя ала. Сез безгә ышаныч өстисез, яхшы эш-гамәлләргә фатиха бирәсез, авыр минутларда терәк буласыз. Тормышыбызда башкарган һәр гамәл Сезнең өчен эшләнә, чөнки Сез – тормыш, мәхәббәт һәм илһам бүләк итүчеләр!

Казан (Идел буе) федераль университетының үсешенә керткән өлешегез өчен тагын бер кат рәхмәт сүзләрен җиткерәсем килә. Икенче туган йортыбыз хатын-кызларының фәнни һәм иҗади үсеш потенциалын арттыруга игътибарны юнәлтү – алдыбызда торган катлаулы һәм амбициоз бурычларны хәл итүнең иң дөрес юлларыннан берсе.

Яраткан, тиңе булмаган гүзәл хатын-кызларыбыз, бәйрәмегез белән тәбрик итәбез! Сезгә ныклы сәламәтлек, иминлек, шатлык телибез!

**Илшат Гафуров,**
КФУ ректоры



✦ Фотода Эрнест Агеев һәм Аделина Тимирбулатова «Чәчәкләр сарае»нда. Влад Михневский фотосы

# *Тиздән, бик тиздән...*

Адым-адым язга кереп барабыз. Һавалар җылына, кояш якыная, күңелләр күтәрелә бара. Ләкин студент халкының вакыты тыгыз: тиздән, бик тиздән махсус стипендияләргә конкурс игълан ителәчәк, «Ягымлы яз», «Студентлар язы» кебек конкурс һәм фестивальләр, күптөрле фәнни-гамәли конференцияләр башланып китәчәк. Институтлар эчендә сайлап алу этаплары дәвам итә. Кызыксынып китсәгез, катнашырга теләсәгез, тулырак мәгълүматны КФУ сайтыннан таба аласыз. Языгыз заяга узмасын!

## ● Вакыйгалар эзеннән

Биохимия институтында 21нче гасыр авыруы – **ИШЕМИЯ ИНСУЛЬТЫНЫҢ ВИВАЛЬ МОДЕЛЕ** төзелгән.

«Ишемия инсульты кичергән кешеләрнең 90 проценты инвалид булып кала. Тик әлеге авыруның килеп чыгу сәбәпләре әлегә чаклы билгеле түгел,» – ди биохимия һәм биотехнологияләр кафедрасы доценты Әлфия Фаттахова. Ярты ел эчендә Ә.Фаттахова, аспиранты А.Веткина белән берлектә, чирнең моделен генә төзеп калмый, ә аның молекуляр башлангычын, дәвалау ысулын да күрсәтә.

Тикшеренү нәтиҗәләре «УМНИК» бәйгесенә тәкъдим ителәчәк.

• • • •

**27** нче **ФЕВРАЛЬ** көнне Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтында **«РЕНЕССАНС»** дип аталган әдәби-иҗади салонның чираттагы **УТЫРЫШЫ БУЛДЫ**. 2015 нче ел Россиядә әдәбият елы дип игълан ителгәнгә күрә, утырыш темасы итеп «Казан университеты поэзиясе»н сайладылар. Университетыбызда 1911 нче елдан бирле «ARS» әдәби берләшмәсе эшләп килә. Берләшмә җитәкчеләре – Николай Беляев һәм Алексей Кириллов. ФА академигы Наил Вәлиев һәм ТР рәссамнар берлеге вәкиле Людмила Купряхина студентларга бүгенге көн рәсем сәнгате турында сөйләделәр, үзләренең тәҗрибәләре белән уртаклаштылар.

Моннан ике ел элек Н.Беляевның Казанда яшәп иҗат иткән авангард рәссам Алексей Аникеенкка багышланган «Поэма солнца» китабы басылган иде. Очрашу вакытында студентлар һәм укытучылар Николай Беляевка үзләрен кызыксындырган сорауларны бирә алдылар.

• • • •

**27** нче **ФЕВРАЛЬ** көнне КФУ диварларында **«IT-ПРОРЫВ»** Дөньякүләм бәйгенең **РЕГИОН КҮЛӘМЕНДӘГЕ ЭТАБЫ БУЛЫП УЗДЫ**. Әлеге чара, «Бердәм Россия» партиясе, «Росэлектроника» АҖ һәм «Softline» компаниясе белән берлектә, 2010 нчы елдан бирле оештырылып килә. Бәйгенең төп максаты – IT технологияләр өлкәсендә эшләүче яшь белгечләрнең интеллектуаль потенциалын арттыру. Катнашучыларның проектлары төп алты номинация буенча тикшерелә. Чараны ачып җибәргән Фәнни эшләр буенча проректор Данис Нургалиев сүзләренә караганда, «IT-прорыв» – зур мөмкинлекләр бирә торган көчле проектларның берсе.

• • • •

**КФУ**ның «Манзара» залында ТР рәссамнар берлеге әгъзасы, халыкара һәм россиякүләм күргәзмәләрдә катнашкан **ЛЮДМИЛА КУПРЯХИНАНЫҢ «КҮҢЕЛЕМ ШИГЪРИЯТЕ»** («Поэзия души моей») дип аталган **ШӘХСИ КҮРГӘЗМӘСЕ** тәкъдим ителде. Чараны С.Сәйдәшев исемендәге Югары иҗат мәктәбе рәсем сәнгате һәм дизайн кафедрасы мөдире Расыйх Сәләхов ачып җибәрде. Реалистик мәктәп вәкилләренең идеяләрен дәвам итеп, Людмила Купряхина картиналарын күпсанлы этюдларга, натурага нигезләнеп эшли.

*Мәгълүмат КФУ матбугат үзәгеннән алынды.*

## ● Гыйльми совет

# Семестр кыскара

26нчы февраль нәтиҗәләр ясау, яңа эшләрне башлап җибәрү өчен уңай көн булды. Нәкъ шул көнне КФУның Кайгыртучанлык советы залында Гыйльми совет утырышы уздырылды.



Инна Басыйрова фотосы

**Университетыбыз ректоры Илшат Гафуров** һәркемне сәламләде, якындагы берничә сәгатьнең – эшлекле очрашуның уңышлы узуын теләде.

2014нче елда фән өлкәсендә башкарылган эшләр турында мәгълүмат белән фәнни эшчәнлек буенча проректор **Данис Нургалиев** чыгыш ясады. Яшь галимнәрнең Scopusта еш басылуларын (гомумән алганда, 1543 мәкалә), ил күләмендә уздырылган грантларда җиңү яулауларын куанычлы күренеш бýларак билгеләде. Тик моның белән генә туктапып калырга тиеш түгеллекне дә ассызыклады. Д.К.Нургалиев әйтүенчә, КФУ студентларының һәм галимнәренең потенциаллары зур. КФУ вәкилләре мәкаләләренең ил күләмендә иң танылган басмаларда чыгуы да – яхшы күрсәткеч. Данис Карл улы фәннең барлык өлкәләре дә бертигез дәрәҗәдә үсәргә тиешлегенә дә басым ясады. Мисалга Хельсинки уку йорты тәҗрибәсе китерелде.

Очрашу вакытында студентларның стипендияләрен арттыру мәсьәләсе дә каралды. Моннан тыш, чит илдә укып, PhD дәрәҗәсенә ия булып, университетыбызга әйләнеп кайткан белгечләр хакында да сүз алып барылды. КФУда эшләүләренең беренче елында мондый белгечләр хезмәт хакларына өстәмә дә алачаклар.

Иң мөһим карарларның берсе – уку семестрының 2-2,5 атнага кыскаруы. 2015нче елның июль-август айларында Казаныбыз кабаттан спорт каласына әйләнәчәк. Шуңа бәйле рәвештә, Гыйльми совет карары нигезендә, җәйге имтиханнар сессиясе 2015нче елның 15нче июнендә тәмамланачак. Чыгарылыш курс студентларының, ягъни специалитет юнәлешендә укучы 5нче курс һәм бакалавриатура юнәлешендәге 4нче курс студентларының, шулай ук магистратураның 2нче курсында белем алучыларның уку һәм имтихан вакытлары үзгәрешсез кала. Дәресләрнең кыскаруы һәм өстәмә дәресләр куелу тәртибен һәр институт һәм факультет җитәкчелеге үзенчә хәл итәчәк. Практика көннәренә дә үзгәрешләр кертелү ихтималы бар. Универсиада авылында яшәүче студентлардан бүлмәләрне 20нче июньгә кадәр тапшырып бетерү соралачак.

## ● Фән дөньясында

Материалларны **Айгөл АБДРАХМАНОВА** әзерләде

# Гыйлем эзен яңартып

Университет яшь галимнәрен барлады. 27нче февраль көнне КФУның Актлар залында «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме – 2014» бәйгесенә йомгак ясалды.



Влад Михневский фотосы

Әлеге чара ТР Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм министрлыгы ярдәме белән, Яшь галимнәр һәм белгечләр оешмасы (сүз уңаеннан, ул быел 10 яшьлек юбилеен билгеләп үтә) тарафыннан алтынчы ел рәттән оештырылды. Оешманың җитәкчесе В.Е.Туманин сүзләренә караганда, биредә 7000нән артык кеше исәпләнә. Димәк, Татарстанда яңа галимнәр үсеп килә, аларның күбесе үзенең киләчәген фәнгә багышларга тели. Яшь галимнәр саны елдан-ел арту, ярышта үзләрен күрсәтергә теләүчеләр арасында яңа шәхесләр күзәтелү сөендерә, әлбәттә.

Бәйгедә катнашучылар үзләрен өч номинациядә сынап карый алдылар: табигый фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим, техник фәннәр өлкәсендә һәм иҗтимагый-гуманитар фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим. Шундый ук өч махсус номинация аспирантурада белем алучылар өчен дә бар. Оештыручыларның сүзләренә караганда, «Татарстан Республикасының иң яхшы яшь галиме – 2014»тә көч сынашучылар алдына ике бурыч куела. Беренчесе, мәкаләләр саны һәм сыйфаты булса, икенчесе – төрле грантларда катнашу. Бәйгегә җибәрелгән йөзләрчә эш арасыннан иң-иңнәрен сайлап алу шактый катлаулы булган. Чөнки һәр яшь галим республикабыз, илебез үсеше өчен мөһим эш башкара икән.

Тантаналы чараны ачып җибәрү һәм катнашучыларны, кунакларны сәламләү өчен сүз КФУның фәнни эшчәнлек буенча проректоры Д.К.Нургалиевка бирелде. Данис Карлович бүгенге көндә кеше потенциалының, акыл хезмәтенең гаять мөһим булуын ассызыклады. «Сәләтле яшьләрне тәрбияләү белән генә чикләнмәскә кирәк. Андыйларны үзендә саклап калган һәм киләчәктә үсү мөмкинлеге бирә алган ил генә чын мәгънәсендә көчле! Биредә – Татарстанның, Россиянең киләчәге!» – диде.

Иҗтимагый-гуманитар фәннәр өлкәсендә иң яхшы аспирант номинациясендә җиңүчеләр: 1нче урын – Е.В. Лунева, 2нче урын – Д.В. Галиуллина, 3нче урын – Д.В. Егоров.

Техник фәннәр өлкәсендә иң яхшы аспирант дип, Н.Н. Жданов танылды. 2нче урында – Г.М. Фәйзрахманова, 3нче урынны А.С. Батраков яулады.

Табигый фәннәр өлкәсендә иң яхшы аспирант исеменә И.Т. Ракипов лаек булды, 2нче урында Э.Д. Солтанова, 3нче урынны Л.Ш. Габдрахманова алды.

Фән өлкәсендә уңышларга ирешкән яшь галимнәрне ТР Фәннәр Академиясе әгъза-корреспонденты, икътисад фәннәре докторы Хаменко Вадим Васильевич бүләкләде.

Иҗтимагый-гуманитар фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим дип А.А. Гыйләҗев танылды. 2 нче урын иясе – М.Ф. Гомәрев, 3нче урын В.Т. Сакаевка бирелде.

Техник фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим дип Н.В. Тимербаев танылды. 2 нче урынны берьюлы ике катнашучы бүлеште: П.А. Кайнов һәм А.Ф. Гайсин, 3нче урында – Р.Х. Мөхәммәтрәхимов.

Табигый фәннәр өлкәсендә иң яхшы яшь галим исеме И.Р. Низамиевка бирелде, 2нче урында – Е.М. Алакшин, 3нче урында – А.С. Овсянников.

## ● Бәйге

# Туган тел тылсымы

**Гөлназ ХАРИСОВА,** Татар теле һәм укыту методикасы кафедрасы доценты

Казан федераль университеты Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Габдулла Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлеге «Туган тел тылсымы» дип аталган эсселар бәйгесе үткәрде.

Бәйгене үткәрү өчен, үзебезнең бүлек укытучыларыннан торган оештыру комитеты төзелде. Жюри әгъзалары итеп, татар теле һәм укыту методикасыкафедрасының яшь һәм тәҗрибәле иҗатчылары, галимнәре һәм мөгаллимнәре сайланды. Бәяләүдә мөмкин кадәр гаделлекне һәм объективлыкны сакларга тырыштык, шуңа да оештыру комитеты эшләрне жюри әгъзаларына шифрлап тапшырды. Эсселар жюри әгъзалары тарафыннан алдан әзерләнгән таләпләр нигезендә 10 ар балл исәбеннән бәяләнде.

Беренче этапта оештыру комитетына барлыгы 138 эш килде. Икенче этапка шуларның 30ы үтте. Алар «Антиплагиат» программасы буенча да тикшерелде һәм оригинальлеге 83 проценттан да кимрәк булганнары конкурстан төшереп калдырылды.

Шулай итеп, «Үрнәк эссе» номинациясендә 3 урын билгеләнде: 1 нче урында – **Батрханова Айзилә** (3 курс), 2 нче урынны **Ибраһимова Алинә** (1 курс) белән **Шангараева Алсу** (1 нче курс), ә 3 нче урынны **Елезарова Юлиана** (1 нче курс) белән **Гайфуллина Илүзә** бүлеште.

Жюри әгъзалары кызыксындыру бүләгенә ия булучыларны да аерым билгеләп үтте: **Шаһиев Ильяс** (3 нче курс), **Мусаткина Анастасия** (3 нче курс), **Гарифуллина Адилә** (1 курс).

Бәйгедә җиңгән студентларга истәлекле бүләкләр тапшырылды, аларга өстәмә балл алу мөмкинлеге дә бирелде.

• Бөек җиңүгә - 70 ел!

# Берлин алган Әлмәндәр

**Раилә ГАЙНУЛЛИНА,** Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

**Кызыклы факт:**
**1945 нче елгы Берлин операциясе тарихта иң зур көрәш буларак Гиннесс рекордлар китабына кертелгән. Бу бәрелештә ике яктан да 3,5 миллионга якын кеше катнашкан дип исәпләнә.**

Быел Бөек Җиңүнең 70 еллыгы бәйрәм ителәчәк. Шуны сәбәп итеп, Тәтеш районы Келәш авылында яшәп ятучы һәм быел 90 яшьлек юбилеен билгеләп үтүче Бөек Ватан сугышы ветераны, авылыбызның аксакалы – Садыйков Ибраһим Вәли улы белән очраштым. Аның истәлекләренә ияреп, әйдәгез әле, шанлы тарихка сәяхәт итик. Колакларга киртләп куелырлык саллы фикерләре бар бит аның!

Ибраһим абый миңа Туфан Миңнуллинның Әлмәндәрен хәтерләтә. Сугыш аша үткән, авыр тормыш кичергән булуына да карамастан, Ибраһим абый тормышка булган мәхәббәтен югалтмаган, кеше белән аралашырга ярата. Янәшәбездә аның кебек кешеләр исән булганда, безнең Ватан сугышын онытырга хакыбыз юк. Килеп керүемә үк, Әлмәндәр карт кебек: «Болай матур итеп киенгәч, бүген танцыга барам инде, анда кызлар киләме икән, кызлар булмагач, танцы булмый инде», – дип, мине көлдереп тә алды. Аннары, аңлатырга теләгәндәй: «Буыннар инде катса да, тел сөйли әле, ул буынсыз бит. Әле дә ярый телгә дә буын куймаганнар», – ди.



**- Ибраһим абый, сугыш еллары хатирәләрен искә алыгыз әле. Сугышка киткәндә сезгә ничә яшь иде һәм кайда хезмәт иттегез? Бераз сөйләп китсәгез иде.**

- Сугыш башланганда, 15 яшьлек егет идек без. 1940нчы елда 14 яшьлек үсмер булсак, сугыш безне буыныбыз белән олыгайтып куйды. Бала-чагалык чыгып бетмәсә дә, үсәргә туры килде. Башта авылның әтиләрен, аннары абыйларны озаттык. 1943 нче елның 7 нче гыйнварендa армиягә безне дә чакырдылар, ул вакытта миңа 17 яшь иде. Безне Ерак Көнчыгышка – Приморский крайга алып киттеләр. Аннан соң, 1944 нче елның сентябрендә, поездларга төялеп, Ленинградка юл тоттык, Луга дигән шәһәргә урнаштык. Луга шәһәрендә безнең полкка тагын бер полкны куштылар да бригада ясадылар. 1945 нче елның март башында Германиядә сугышка кердек. Котбус янында бер атна оборонада тордык, соңыннан бу шәһәрне кулга төшердек. 1945 нче елның 2 нче маенда Берлинны алдык. Төштән соң Берлиннан чыктык, Дрезден шәһәренә килдек. Ике яктан ут позицияләре корып, атыштык та сугыш бетте. Ул көн 9 нчы май иде инде. Кыскача гына сөйләгәндә, шулай. Кан, күз яше – аларын сөйләп тә тормыйм.

*Сугыш безнең өчен 1945 нче елда бетмәгән иде әле. Өйгә 1950 нче елның апрель аенда гына кайттым.*

**- Сугыш беткәч, туган якларга кайтып киттегезме?**

- Сугыш безнең өчен бетмәгән иде шул. Аннары Берлинда җәй үткәрдек, көз көне Венгриягә күчерделәр, Хаймашкер шәһәренә, анда кышладык. 1946 нчы елның апрель ахырында поезд белән Украинага кайттык. Анда 1947 нче елгы ике парадта катнаштым –1 нче май һәм 7 нче ноябрь бәйрәмнәре иде. Аннан Сумская областька күчерделәр, шунда 5 ел хезмәт иттем. Өйгә 1950 нче елның апрель аенда кайттым. Рядовой составны 1949нчы елны кайтардылар, ә мин, сержант булганга, тагын бер ел хезмәт иттем.

**- Хезмәт итеп кайткач, нәрсә белән шөгыльләндегез?**

- Октябрь аенда Казанга авыл хуҗалыгы, колхоз һәм совхоз җитәкчеләре әзерли торган училищега укырга киттем. Өч елдан соң, кызыл диплом алып чыктым, читтән торып Авыл хуҗалыгы институтында укыдым. Үзебезнең авылда 39 ел колхоз председателе булып эшләдем. СССРның Югары Советына депутатлыкка сайландым, Ленин ордены, Почет билгесе ордены белән бүләкләндем, Халык мәгарифе отличнигы дигән исем алдым.

**- Киләчәк буынга нинди теләкләр теләр идегез?**

- Күп итеп укысыннар, яхшы хезмәт итсеннәр. Авылыбыз өчен тырышсыннар, авыл таза булса, халыкка яшәргә әйбәт була. Техниканы өйрәнсеннәр, хәзер техника заманы. Исәнлек телим, Ходаем барысына да шатлыклы озын гомер бирсен, шатланып яшәргә насыйп итсен. Исән-сау йөрсеннәр, гаиләләрендә матур, тыныч тормыш корсыннар.

Бүгенге көндә Ибраһим абый хатынын һәм ике улын җирләгән. Тормышның бу авырлыкларын җиңәргә аңа ике кызы, биш оныгы, өч оныкчыгы ярдәм итә. Аксакалыбызның, бернигә дә карамастан, көләч йөзле, тормыш сөючән, җор телле булып кала алуы тормыштан зарланучыларга үрнәк булсын иде.

• Чара

# «Безне сәнгать берләштерә»

**Илмир ВӘЛИЕВ,** Математика һәм механика институты

27нче февраль көнне УНИКС концертлар залында иң матур җырлардан, иң дәртле биюләрдән, иң якты чыгышлардан гына торган Colours of the world at KFU халыклар дуслыгы фестиваленең Гала-концерты узды.

Төрле халыклар арасында гасырлар буе камилләшеп килгән дуслык – безнең кыйммәтле мирасыбыз. Бүгенге көндә университетыбызда 2106 чит ил студентының белем алуы моның шулай икәнлеген тагын бер кат дәлилли.



Быел өченче мәртәбә узучы чит ил студентлары фестиваленең Гала-концертында Таҗикстан, Кытай, Үзбәкстан, Куба, Конго Демократик Республикасы һ.б. милли җәмгыятьләрнең театральләштерелгән тамашалары күрсәтелде. Кичә матурдан-матур халык җырлары, бию композицияләре белән үрелеп барды. Моннан тыш, фойеда катнашучы илләрнең милли мираслары тәкъдим ителгән күргәзмә өстәлләре белән дә хозурланырга мөмкин иде.


Тышкы элемтәләр буенча проректор Линар Латыпов милли телләрнең күп булуына карамастан, рус теленең берләштерүче, уртак булуын, чит ил студентларының университет диварларында рус телен дә югары дәрәҗәдә өйрәнә алачакларын ассызыклады. «Телебез, гореф-гадәтләребез, яшәешебез, милләтебез төрле, әмма безнең барыбызны да сәнгать берләштерә», - дип тәмамлады үз чыгышын Л.Латыпов.

Проректор сүзләре белән килешмичә булмый: сәнгать – КФУ студентларының алыштыргысыз «коралы», чөнки бирелә сәнгатькә гашыйк студентлар укый. Шуңа да сәнгать безгә бер-беребезне аңлап, хөрмәт итеп яшәргә булыша.

Фестиваль кысаларында, түгәрәк өстәлләр, күргәзмәләрдән тыш, җәмәгатьчелек һәм спорт чаралары да уздырылган иде. Гала-концертта аларга нәтиҗә ясалды. Теннис, шахмат һәм мини-футбол кебек спорт төрләре буенча җиңү яулаган студентларны сәхнә түрендә тәбрикләделәр.

УНИКС залы студентлар, килгән кунаклар белән шыгрым тулы иде. Ә чарадагы бәйрәм атмосферасы студентлар арасындагы дуслык җепләрен тагын да ныгытты. Тамашачылар чыгышлар вакытында күрсәтелгән видеороликлар аша төрле халыкларның яшәү рәвеше белән танышты, аларның истәлекле урыннарын күзәтте.

Оештыручылар сүзләре буенча, фестивальнең төп бурычы – студентларның иҗади сәләтләрен ачу, мәдәни элемтәләрне ныгыту һәм чит илләрнең милли традицияләре белән танышу.



Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Г.Тукай исемендәге татар филологиясе һәм мәдәниятара багланышлар бүлегендә Шәехзадә Бабичны искә алып уздылар. 25нче февраль көнне шагыйрьнең 120 еллык юбилеена багышланган әдәби-музыкаль кичә булды.

# Бабич рухы яши күңелләрдә

**Светлана ГЫЙЛӘҖЕВА**

Әлеге чараны шушы бүлекнең мөгаллиме Таһир Шәмсегали улы Гыйлаҗев җитәкчелегендә бер төркем студентлар оештырдылар. Махсус кунак итеп, Шәехзадә Бабичның шәхесен, иҗатын тирән итеп фәнни яссылыкта өйрәнгән галим, язучы Галимҗан Гыйльманов чакырылган иде. Ул күренекле шагыйрь Шәехзадә Бабичның тормыш юлы, эшчәнлеге турында бик кызыклы чыгыш ясады. Күбебез әлеге әңгәмәдән соң шагыйрьне үзебез өчен бөтенләй башка яктан ачты. Яшьли үк белемгә, мәгърифәткә омтылып яшәгән, шуны халыкка җиткерүне максат итеп куйган Шәехзадә Бабичны бөек Тукайның дәвамчысы дип әйтергә була. Шагыйрь үзенең иҗаты белән генә түгел, сәясәт өлкәсендәге эшчәнлеге белән дә аерылып тора.

Кичәне 5нче курс студенты Якупова Лилия алып барды. 3нче курс студентлары Вәлиева Альбина, Вәлиева Назлыгөл шагыйрьнең тормыш юлына кагылышлы фактлар белән таныштырып үттеләр. 1нче курс студентлары Сәләхова Алсу, Фатихова Чулпан, 3нче курс студентлары Җамалетдинов Нияз, Заһидуллин Рәдифләр башкаруында Шәехзадә Бабичның шигырьләре исә тамашачыларның күңелләренә уелып калды.

Чара, күңелләргә хуш килеп, күпчелектә күренекле шагыйребез Шәехзадә Бабичның иҗатына кызыксынуны арттырды. Әлеге очрашуны оештырып, матур итеп алып баручыларга барлык тамашачылар исеменнән дә зур рәхмәт җиткерәсе килә! Алга таба да мондый чаралар булып торсын.

● Таныш бул!

# Иң-иңнәрдән беренче!

Руфинә ГАБДРАХМАНОВА

Ничек уйлыйсыз: идеаль 5нче курс студенты нинди булырга тиеш? Ул – яхшы укучы, фәнни-гамәли конференцияләрдә катнашучымы? Әллә ул күбрәк спорт белән кызыксынырга, җәмәгать эшләрендә актив булырга тиешме? Бәлки, идеальлекне билгели торган башка күрсәткечләр бардыр?

Безгә ул кадәресе билгеле түгел. Тик без күпләргә үрнәк була алырлык, зур уңышларга ирешеп тә, үзен төрле яктан үстерергә омтылучы студентны барларга тырыштык. Һәм андый сыйфатларга Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының 5 нче курс студенты Рөстәм Шәмсетдинов ия икән дигән фикергә килдек.

**- Рөстәм, татар филологиясен сайлавыңа нәрсә тәэсир итте?**

- Дөресен генә әйткәндә, бик кызыклы һәм көтелмәгән рәвештә килеп чыкты ул хәл. Татар-төрек лицеен бетереп, Анапа югары уку йортына керү теләге белән янып йөри башладым. Март азагында документларны тиешле урыннарга тапшырдык, укырга керүче кешеләр исемлегенә эләктем. Ләкин кайбер сәбәпләр аркасында китә алмыйча калдым. Тиз-тиз генә документлар җыйдым да татар филологиясенә килдем. Казанда кайсы уку йортына, нинди факультетка барырга дигән сорау тумады.

**-Күптәнтүгелгенәсинең А.А.Вознесенский исемендәге стипендия лауреаты булуың ачыкланды. Мондый бәйгедә катнашу мөмкинлеге турында каян белдең?**

- Кызганычка каршы, мәгълүмат киң аудиториядә яктыртылмады. Ләкин үз вакытында КФУ сайтына кергән студентлар А.А.Вознесенский исемендәге стипендия нигезләмәсе белән таныша алганнардыр. Фәнни җитәкчем – Ашрапова Алсу Хәлил кызы ярдәме белән кирәкле документларны җыеп җибәрдек.

**- Бәйгенең шартлары нинди иде?**

- Бездән портфолио соралды. Әдәбият өлкәсендәге фәнни язмалар, фәнни-гамәли конференцияләрдә һәм уку йортының мәдәни тормышында актив катнашу кирәк иде. Үз эшләремне китергәндә, беренче кеше булмавыма игътибар иттем. Калын портфолиолар китергән кешеләр шактый иде.

**- Стипендиат булуыңны каян белдең, ничегрәк кабул иттең?**



- Әле яңарак кына А.А.Вознесенский стипендиясен алучылар турында университетыбыз сайтында приказ чыкты. Шуннан белдем. Хисләргә килгәндә... нәрсә булганын тулысынча аңлап бетерә алмыйм әле. Күрәсең, вакыт кирәк.

**- Стипендиат булу сиңа һәм әйләнә-тирәдәгеләреңә ничек тәэсир итте?**

- Миндә бернинди дә үзгәреш юк. Әйләнә-тирәдәгеләргә стимул булгандыр дип өметләнәм.

**- Рөстәм, син бит әле күптән түгел генә Төркиядә укып кайттың. Ничек китәргә булдың? Кай арада өлгерәсең?**

- Әйе, дөрестән дә шулай. Чит илдә, бигрәк тә Төркиядә белем аласы килү теләге күптән бар иде инде. Татар-төрек лицеен бетергән кеше буларак, тел белән авырлыклар чыкмады. Үзебезнең уку йортыбызның Халыкара бүлегенә барып, белергә теләгән мәгълүмат алдым да, кәгазь мәшәкатьләренә күчтем.

**- Нинди хисләр белән яшисең?**

- Әзрәк кенә борчылу бар. 5нче курс, дәүләт имтиханнары, чыгарылыш квалификациясе эше язу мәшәкатьләре белән яшим әлегә. Эш эзләргә кирәк дигән уй башымнан чыкмый. Җиткән егеткә эшсез утыру килешми дип саныйм.

**- Үзеңне нинди эштә күрәсең?**

- Беренче чиратта, мөгаллим, әлбәттә. Вакытлыча, өстәмә дәресләр бирергә (репетиторство), яки тел курсларында укытырга мөмкин булыр иде.

**- Җәйгә планнарың нинди?**

- Су төрләре буенча Дөнья Чемпионатында тәрҗемәче булып эшлисем килә.

**- Башка студентларга әйтәсе килгән теләгең, фикерең?**


- Тормыш – ул җаваплылык. Үзең, дусларың, туганнарың өчен җаваплылык. Башкаларга үрнәк булырга тырышырга кирәк. Һәр башкарган эшне күңел биреп эшләгез, ахырдан ләззәт алырлык булсын. Безне әйләндереп алган чүп-чардан арыныгыз, шәхси үсешкә ярдәм итә торган әсәрләр, кинолар белән генә кызыксыныгыз. Идея белән яшәргә өйрәнү кирәк, чөнки идеяле кешегә бернинди тотрыксызлык та тәэсир итми. Мәктәпкә барырга теләүче студентларга аерым бер үтенечем бар: балаларда фәнгә карата мәхәббәт уятсыннар һәм уйларга өйрәтсеннәр иде.

Автор фотосы

**✦ Безнең белешмә:**

*Туган урыны:* **Кукмара районының Кәркәүч авылы**
*Туган вакыты:* **8 март, 1992нче ел**
*Хобби:* **җырлый, футбол уйный**
*Яраткан төсе:* **ачык яшел, кызыл**
*Кешеләрдә өстен күргән сыйфатлар:* **олы жанлылык, фидакарьлек, билгеле бер идея белән яшәү**
*Тормыш шигаре:* **«һәр эшнең бер хәере бар»**.

● Әдәби сәйләннәр



Зәмирә ВАХИТОВА,
Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты

## Яз өчен...

*Күңелдә – яз,*
*Урамда – яз,*
*Шәһәрдә язгы һава...*
*Соңгы кышкы болытлардан*
*Тып та тып яңгыр ява.*

*Җир җылына,*
*Җан җылына,*
*Тик синең караш суык.*
*Я әйт әле, ничек кенә*
*Каласың суык булып?*

*Мин беләзем, ул юк дисең,*
*Үткән-барган сораса...*
*Ярар, шулай ерагай син,*
*Безгә шулай яраса.*

*Яз күңелгә сөю бирә,*
*Яз бит сөю заманы.*
*Нигә безнең хисләр аксый,*
*Нигә җаннар яралы?*

*Язлар көлеп караганда,*
*Моңсу булу ярамый.*
*Ялгыш сүзләр әйтсә чит-ят,*
*Күңелләрне каралый.*

*Мин кышымны озатам да*
*Кояшлы язга керәм.*
*Ә син сагын,*
*Сагынырсың...*
*Һәм кайтырсың бит – беләм!*

*Тып-тып итеп яңгыр ява,*
*Җир ана да яшәрде.*
*Моңсу чакны тиз-тиз узып,*
*Язлар өчен яшәрмен.*

● Котлаулар

**Линар ЗАКИРОВ,** Иҗтимагый фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институты

Хөрмәтле укытучыларыбыз, университет хезмәткәрләре, кызлар-йолдызлар! Сезгә караганда, күктәге йолдызлар, хәтта Җидегән йолдыз белән Айга менеп кунаклаган Зөһрә кыз да тонырак күренә сыман. Илһам кирәккәндә дә (хәер, кирәкмәгәндә дә!) без күккә карап ятмыйбыз, Сезгә бер караш ташлау җитә. Йокымсырап яткан каләм шунда әпипә биегәндәй эшкә керешә. Сездә журналистларга иң кирәкле сыйфатларның берсе – сизгерлек болай да чиктән ашкан, шуңа да Сездән берни яшереп булмый. Хәер, якын кешеләрегез арасында яшерерлек серләр мөмкин кадәр азрак булсын. Тормышыгыз «Дәрелфөнүн» газетасы кебек кызыклы, «Ялкын» журналының аллы-гөлле битләре сыман җете мизгелләргә бай булсын, «Сөембикә» журналы шикелле һәрчак зәвыклы, «Казан утлары» журналы сыман озын гомерле булыгыз һәм укуда да, эштә дә «Шәһри Казан» газетасы сыман гел кайнап торырга язсын Сезгә!



**● Данис Җамалиев**
**КФУ, Информацион технологияләр һәм информацион системалар югары мәктәбе**

*Яраткан хатын-кызларыбыз! КФУның ИТИС студентлары исеменнән Сезне 8 нче март бәйрәме белән тәбрик итәм. Яратып һәм яратылып яшәргә, һәрчак гүзәл, сөйкемле булып калырга язсын. Яраткан кешеләрегезгә карата һәрчак ихлас булсагыз иде. Ә без исә, үз чиратыбызда, Сезне бәхетле итү өчен бар көчебезне куячакбыз.*

**● Рәдиф Әхмәдиев**
**Халыкара мөнәсәбәтләр, көнчыгышны өйрәнү һәм тарих институты**

*8 нче март – гади көн түгел. Замбия дәүләтендә – яшьләр көне, Албаниядә – укытучылар көне. Немец астрономы Иоганн Кеплер да планеталар хәрәкәтенең 3нче теориясен шул көндә тәкъдим итә. Кыскасы, вакыйгаларга бай көн. XX гасырдан башлап, 8 нче март бар дөньяда Халыкара хатын-кызлар көне буларак билгеләп үтелә. Форсаттан файдаланып, дөньяның иң күркәм, затларын бәйрәмнәре белән котлыйм. Барлык хатын-кызларга гаилә бәхете насыйп булсын!*

**● Раниф Гарифуллин**
**Информацион технологияләр һәм исәпләү математикасы институты**

*Хөрмәтле әниләр, кызлар һәм апалар! Сезнең барыгызны да 8 нче март – Халыкара хатын кызлар көне белән котлыйм. Сезгә бәхетләрнең иң олысын, шатлыкларның иң зурысын, мәхәббәтнең сафын, гаилә тынычлыгы телим. Һәр туар таң Сезгә бары тик шатлык-куанычлар гына алып килсен. Сез булганда, дөнья ямьлерәк, күркәмрәк.*

**● Булат Солтанбәков**
**Иҗтимагый фәлсәфи фәннәр һәм массакүләм коммуникацияләр институты**

*Хөрмәтле хатын-кызларыбыз! Сезне Халыкара язбәйрәме белән котлый алуыма чиксез шатмын! Янәшәдә әни, апа, дәү әни, хәтта иптәш кызларның булуы – зур бәхет. Сез – безнең ышанычыбыз, терәгебез, гомумән, Сез – бар дөньябыз!*

DARELFONYN УНИВЕРСИТЕТ
Тираж 1000
Газета бушлай таратыла

Мөхәррир - Динара Равил кызы Миннекаева
Иҗат коллективы: Э.Р.Һадиева
Корректор - Р.А.Асылгәрәева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч - Г.З.Камалиева

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37 йорт, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru Сайт: kpfu.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00
«Фолиант» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Профсоюзная, 17в.